**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әсәй авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Әсәй авылы № 15 «11» сентябрь 2017 ел

Референдум уздыруны инициацияләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әсәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә,

Әсәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум уздыруны инициацияләргә:
“ Сез, 2018 елда Әсәй авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 250 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару өчен үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:
1) Әсәй авылы, Митрәй авылы юлларында кар чистарту;
2) авыл җирлеге территориясендә чүп-чардан арындыру;
3) Бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру;
4) Су үткәрү челтәрләрен ремонтлау;
5) янгын сүндерү бүлегенең электр энергиясе, янгын сүндерү машинасын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү;
6) Митрәй авылы мәдәният йортын ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны түбәндәгеләргә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә тиеш:
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының түбәндәге адрес буенча урнашкан Әсәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендлары:
ТР, Азнакай муниципаль районы,Әсәй ав., Үзәк ур., 38Б.
- түбәндәге веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы: http://pravo.tatarstan.ru, адресы буенча
- Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында түбәндәге веб-адрес буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Рәис Л.М. Вәлиева